ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» март 2020 ел № 85

**Әгерҗе муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында уку чорында укучыларны тукландыруны оештыру һәм туклану өчен түләү буенча акчасыз исәп-хисапка күчү турында**

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында" 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2008 елның 23 июлендәге 45 номерлы карары белән расланган «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.4.5.2409-08 СанПиНы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының ата-аналар комитетлары карарлары нигезендә, шулай ук Әгерҗе муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны укыту чорында туклануны оештыру һәм тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 апреленнән билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында бер укучыга бер көнгә туклану бәясен 37 сум 70 тиен дип, шул исәптән:

- уку чорында бер укучыга бер көнгә 7 сум 70 тиен күләмендә субсидия;

- уку чорында бер укучыга бер көнгә ата-аналар кертемнәре суммасы 30 сум 00 тиен күләмендә.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә уку чорында Әгерҗе муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларына азык-төлек продуктларыныц өзлексез килүен координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең контракт хезмәтенә Әгерҗе муниципаль

районы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә кредит учреждениеләре (банклар) белән акчасыз исәп-хисап буенча туклану өчен түләү счетларын ачуга килешүләр төзүдә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

4. Әгерҗе муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- азык-төлек белән тәэмин итү максатыннан мәктәп буфетын оештыру өчен Әгерҗе муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары биналарында мәйдан бүлеп бирергә һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән килештереп аренда килешүләре төзергә;

- Әгерҗе муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә туклануны оештыруны көн саен контрольдә тотарга;

- туклану сыйфатын һәм Әгерҗе муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының азык-төлек блокларының санитар торышына туры килүенә СанПиН 2.4.5.2409-08 таләпләрен үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

6. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль бюджет учреждениесенә Әгерҗе муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклануны оештыру һәм тәэмин итүгә кирә торган акчаларны максатчан куллану һәм исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**